ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.04.2018 Казан ш. № 10-7/кс

2018 елга кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системаларындагы кайнар суга тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кайнар су белән тәэмин итүче оешмаларга бирелә торган кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системаларындагы кайнар суга тарифларны әлеге карарга кушымтада каралган календарь бүленеш белән билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергән көннән башлап 2018 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.
3. Әлеге карарга кушымтада каралган кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешмаларга Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән дә соңга калмыйча, һәркем өчен ачык булырга тиешле мәгълүматны ачарга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
2018 елның_20 апрелендәге 10-7/кс
номерлы карарына кушымта

# Кайнар су белән тәэмин итүче оешмаларга бирелә торган кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системаларындагы кайнар суга тарифлар, 2018 елга календарь бүленеш белән

| № т/б | Муниципаль берәмлекнең, кайнар су белән тәэмин итүче оешманың исеме | Кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасында кайнар суга тарифлар (ике компонентлы) . | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Салкын суга компонент, сум/куб.м | | Җылылык энергиясенә компонент, сум/Гкал | |
| | | карар үз көченә кергән көннән алып 2018 елның 30 июненә кадәр | 2018 елның 1 июленнән алып 2018 елның 31 декабренә кадәр | карар үз көченә кергән көннән алып 2018 елның 30 июненә кадәр | 2018 елның 1 июленнән алып 2018 елның 31 декабренә кадәр |
| | Әлмәт муниципаль районы | | | | |
| 1 | «Светсервис» муниципаль унитар предприятиесе | | | | |
| 1.1 | Башка кулланучылар (тарифлар НДСны исәпкә алмыйча күрсәтелгән) | 37,35 | 37,35 | 1968,61 | 2005,65 |
| | Питрәч муниципаль районы | | | | |
| 2 | «Теплострой» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте* | 20,67 | 21,54 | 1527,65 | 1572,06 |

<*> оешма салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тарифларны кабул итүне оештыру, тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге